**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16.04. 2021 ел** **№ 100**

**Торак урыны мәйданының исәп-хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бер гражданга гомуми торак урыны мәйданының 18 кв. метры күләмендә бирү нормасын билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә социаль наем һәм Дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының 16.06.2006 елдагы № 159 карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Каюмов